

Яна һәм иске урыннарда, безнен гажәпкә каршы, Большеберезник районы Нерлей ягында каен гомбәсе - подберезовиклар чиләге белән жыйдык, дип сойлиләр. Анда берничә подосиновик та табылган.
Наталья Моисеева унышлы ау белән vзенен ВКонтакте битендә vткән атна мактанган иде инде. Ромоданово районы Липки урманыннан подосиновиклар белән бергә, бер ак гомбә дә тапканнар. Мордовия гомбәчеләре Старошайгово, Кадошкино районындагы гомбә урыннары быел әлегә кадәр коры иде, диләр. Аномаль эссе жәйдән сон нык кипкән гомбәлекләрне активлаштырырга янгырлар яуса да, әлегә бик ук житешле дәрәжәдә тvгел. Шуна да урманнарда 4 класс янгын курнычы бар әлегә, диләр. Сак булыгыз!      Бvгенгә янгырлар Мордовиянен торле районнарында яуды, гом-бәләр чыкты, хәтта горереждә (грузди) дә; аларны кисеп жыясымы, әллә борыпмы, дигән сорау туа. Микологлар әйтvенчә, аерма юк. Тамыр системасына тегеләй итсән дә, болай итсән дә зыян килми. Гомбә тамыры - доресрәге гомбәлек - миллиард жепселләрдән гыйбарәт, аларнын бер олеше vлеп, даими янарып тора. Пычак белән кисеп жыю унайлырак.
Авыл хужалыгы белән интенсив шогыльләнгән кырлар янындагы агачлыклардан гомбә жыярга кинәш ителми. Ашлама керткәндә һәм корткыч божәкләргә каршы эшкәрткәндә гомбәлекләр кеше очен агулы матдәләрне vзләренә жыя. Шул ук сәбәп аркасында гомбәне автомобиль трассаларыннан һәм тимер юл буйларыннан да жыймау хәерле. Гомумән алганда, шәһәрдән 50-100 чакрым ераклыкта (экологик яктан чагыштырмача чиста жирлекләрдә) жыйсагыз, агулану куркынычы кимрәк.
Катнаш урманнарда торле гомбәләр vсә. Бер гомбә очратсагыз, китмәгез, анын яныннан гомбәнен зур «гаиләсен» эзләгез, чонки жир астында тамыр системасы - гомбәлек колач жәйгән була. Ә жыйган унышны кәржингә яшь һәм нык, кортсыз гомбәләрне генә салыгыз. Бер генә кортлысы булса - барысын да сәгать эчендә кортлата. Чебен личинкалары һәм курчак метаболитлары гомбәне агулап, кешегә зарар китерә ала. Ойгә кайту белән эшкәртергә жай чыкмаса, гомбәне суыткычка куеп торыгыз, әмма бер

тәvлектән дә озаграк тотмагыз - гомбә озак сакланмый. Бары тик жәймәле горeждә (пластинчатые грузди), әтәч гомбәсе, баллы гомбә (опята) генә биш конгә кадәр сакланырга момкин. Әйтеп китәргә кирәк, грузди-горәждә гомбәсе калкып чыкты, торле урманнарда (фото «Грибники Мордовии» сайтыннан алынды) жыялар.
Гомбә жыйгандагы алтын кагыйдәләрне онытмагыз - белмәгән, танымаган гомбәне алмаска! Мордовиядә меннән артык гомбә торе очрый. Тәжрибәгез булмаса, һәрвакыт тәжрибәле юлдаш ияртегез. Гомбә жыя башлаганда ин еш очрый торган оч гомбәне аерырга ойрәнегез: ак, каен, усак гомбәсе - башта шуларны гына жыеп карагыз.
«Дошманны» танып белергә кирәк. Агулы гомбәләрнен топ билгеләре: эшләпәсендә ябышкак кунык (липкий налет) була, тәмсез исле, кискән урынында тосе vзгәрә, тобе аска таба юаная, тобендәге юанаеп киткән, кvкәйсыман формада урыны була, сабында божра - якасы була.
Үзегез таныган ашарга ярак-лы гомбәләрне танымаган, шикле гомбәләр белән бергә салмагыз һәм аларны бер ук пычак белән кисәргә ярамый.

**Н.ХӘЛИЛ**